**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 октябрь № 747

г. Казань

2017 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирә торган дәүләт мәгариф оешмаларында төп белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирә торган дәүләт мәгариф оешмаларында төп белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен (карарга теркәлә) расларга.

2. Социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләрнең бу карар белән расланган күләмнәре барлык милек рәвешендәге һәм теләсә кайсы ведомствога караган белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары, урта звено белгечләрен әзерләү программалары, бакалавриат программалары, белгечләр әзерләү программалары, магистратура программалары буенча белем алучы укучыларга кагыла, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм

калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2015 ел, 3 октябрь, 738 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 13 октябрь, 747 нче
карары белән расланды

2017 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирә торган дәүләт мәгариф оешмаларында төп белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре

| Т/с | Социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр исеме | Түбәндәге программалар буенча белем алучыларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре, сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү | урта гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү | урта звено белгечләрен әзерләү | бакалавр, белгечләр, магистрлар әзерләү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Белем бирү оешмасын тәмамлап чыкканда ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга бер тапкыр бирелә торган пособие | 694 | 694 | 694 | 694 |
| 2. | Белем бирү оешмасын тәмамлап чыкканда ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала- | 59 337 | 59 337 | 59 337 | 59 337 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | лар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие | | | | |
| 3. | Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга уку әдәбияты һәм язу әсбаплары сатып алуга еллык пособие | 2 482 | 2 482 | 2 482 | 6 424 |
| 4. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие | 25 289 | 25 289 | 25 289 | 25 289 |
| 5. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга белем алучылар өчен 2017 елның 1 сентябренә кадәр билгеләнгән стипендия күләменнән арткан күләмдә айлык стипендия | 816 | 816 | 816 | 816 |
| 6. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан | 856 | 856 | 856 | 856 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга белем алучылар өчен 2017 елның 1 сентябреннән билгеләнгән стипендия күләменнән арткан күләмдә айлык стипендия | | | | |
| 7. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга туклану өчен айлык пособие | 6 094 | 7 023 | 7 023 | 7 023 |

_______________________________